ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

06 02 2023 г. № 106

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Түбән Кама муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә йөрүче балалары булган аерым категория гражданнарга өстәмә социаль ярдәм күрсәтү чаралары турында» 2016 елның 4 маендагы 874 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, шулай ук мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы Түбән Кама муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә йөрүче балалары булган аерым категория гражданнарга өстәмә социаль ярдәм күрсәтү максатларында, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Түбән Кама муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә йөрүче балалары булган аерым категория гражданнарга өстәмә социаль ярдәм күрсәтү чаралары турында» 2016 елның 4 маендагы 874 номерлы карарына (алга таба – карар) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карарның 1 пунктын түбәндәге эчтәлекле абзацлар белән тулыландырырга:

«2023 елның 1 февраленнән мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы Түбән Кама муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә йөрүче балалары булган түбәндәге категория гражданнарга балаларны караган һәм тәрбияләгән өчен ата-аналар түләвенең бер өлешенә өстәмә компенсация билгеләргә:

- ата-анага -махсус званиесе булган һәм Россия Эчке эшләр министрлыгының Түбән Кама муниципаль районы буенча идарәсендә хезмәт узучы Россия Эчке эшләр министрлыгының Түбән Кама муниципаль районы буенча идарәсе хезмәткәренә.»;

карарга кушымтада:

1.3 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«- ата-анага -махсус званиесе булган һәм Россия Эчке эшләр министрлыгының Түбән Кама муниципаль районы буенча идарәсендә хезмәт узучы Россия Эчке эшләр министрлыгының Түбән Кама муниципаль районы буенча идарәсе хезмәткәренә.»;

2.1. пунктының дүртенче абзацыннан соң түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«- эш урыныннан белешмә һәм Россия Эчке эшләр министрлыгының махсус званиесе булуын раслаучы документ (Россия Эчке эшләр министрлыгының Түбән Кама муниципаль районы буенча идарәсе хезмәткәрләре өчен).»;

2.6 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«- Россия Эчке эшләр министрлыгының Түбән Кама муниципаль районы буенча идарәсе хезмәткәре белән контрактны туктату яки өзү.».

3. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Түбән Кама муниципаль районы Уставында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.Г. Мәхмүтовка йөкләргә.

Җитәкче Р.Ф. Булатов